ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 05 сентябре № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Рощаавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2016 елның 06 апрелендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Рощаавыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 маддәсе нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указының 8 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Рощаавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Рощаавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2016 елның 06 апрелендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә::

8 пунктта «2014 елның 19 ноябрендәге 55 номерлы» сүзләрен «2018 елның 05 июлендәге 44 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур.,1 йорт (Мингәрәев АКЦ бинасы), Спиридоновка авылы, Совет ур., 32 йорт (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы А.А.Потапов